**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№541**
**29.01.2021**

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатында, аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтләрен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондындагы торак урыннары бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатында, 2021 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 10 642 сум 29 тиен;

2) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 970 542 сум;
- ике кешедән торган гаилә өчен – 1 941 084 сум;
- өч кешедән торган гаилә өчен –2 911 626 сум;
- дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 882 168 сум;
- биш кешедән торган гаилә өчен – 4 852 710 сум;
- алты кешедән торган гаилә өчен – 5 823 252 сум;

- җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 793 794 сум;
- сигез кешедән торган гаилә өчен – 7 764 336 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов